**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

____________ № _________

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегендә каралганча, 6964,68 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 гыйнварындагы ПР-13 номерлы карарын 2021 елның 01 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Л.Ф.Нурлыева

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына
«__»__________ ______ ел, № ПР -___
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында
2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең
гарантияләнгән исемлеге бәясе

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе-(сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 100 |
| 2. Кәфенләү | 300 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 1500 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү | 1389,70 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 3674,98 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |